**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, с.Базарные Матаки,
ул. С.Крайнова, д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С. Крайнов ур., 58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Базарлы Матак авылы

2024 нче елның 12 апреле 261№

Әлки муниципаль районы Советы 2021 елның 1 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 71 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Советы 2021 елның 01 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 71 номерлы карарына (2021.12.20 83№ , 2022.02. 11 93№ редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Әлеге карарга 1 нче номерлы кушымта нигезендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген расларга.

2. Әлки муниципаль районы Советының 15.11.2023 елның 228 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында https://alkeevskiy.tatarstan.ru һәм "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan.ru.порталында" урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны агросәнәгать комплексы, экологик иминлек һәм табигатьтән файдалану мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль
район Башлыгы А.Ф.Никошин

СОВЕТ АЛЬКЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
ИНН 1606004125

Әлки муниципаль район
Советы карарына
Кушымта

12.04.2023 261 №

**Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының өч ай рәттән ике һәм аннан да күбрәк беркетмәләре муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Россия Федерациясе Торак Кодексының 165 маддәсының 5 өлеше нигезендә билгеләнгән тәртипкә, рәвешләре, срокларга һәм вакытлычалыкка ярашлы рәвештә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматның өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында актуальләшмәве.

3. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырыла.

4. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрне ачыклау.